Насыйбуллина, Р. "Яхшымы-яманмы, мин шулай язам" / Р. Насыйбуллина; [әңгәмәдәш] С. Гарипова // Шәһри Чаллы. – 2025. – №59 (15 август). – Б. 16.

# «Яхшымы-яманмы, мин шулай язам»



**Журналист, тәрҗемәче, шагыйрә Рәзинә Насыйбуллина исеме Чаллыда күпләргә таныш. Татар журналистикасына куйган фидакяр хезмәте өчен 2008 елда ТР атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булды. «Әрем исе», «Зәңгәр Ыгым хыялымда» дигән китаплар, 40 ка якын җырлар авторы. Өченче шигырьләр китабын нәшриятка әзерли.**

**- Рәзинә апа! Сез шигърияткә оҗмахка тиң ямьле Ык буйларыннан килеп кергәнсез. Тик, ни кызганыч, туган авылыгыз да, ата-ана корган нигезегез дә юк бүген. Бик күп шигырьләрегез, бигрәк тә башлангыч иҗатыгыз шул үзәк өзгеч югалту ачысы белән сугарылган.**

- Әйе, 1971 елда туган авылым Чебенле, Ык буена утырган 20ләп авыл белән бергә, Чулман суы астында калды. Түбән Кама ГЭСының куәтен арттыру безне туган җирсез калдырды. Мәңге үтми торган сагыш, мәңге төзәлми торган яра ул. «Саклап булмады» дигән шигыремә мәрхүм Ринат абый Гобәйдуллин көй дә язган иде.

**- Ә халык ничек кичерде бу югалтуны?**

- Әлеге хәсрәт безне берләштерде, дисәм, һич ялгыш булмас. Һәр елны Чулман ярындагы хәтфә тугайда Чебенлебезнең Хәтер көнен үткәрәбез. Ак мәрмәр һәйкәл алдында дога кылабыз. Аннан соң елашып-җырлашып, хатирәләрне барлыйбыз. Тезелешеп утырып, тәмле ботка ашаганнан соң, изге теләкләр юллап, саубуллашабыз. Бу очрашулар бит һәр Чебенле кешесе өчен изге йолага тиң.

**- Сезнең талантыгыз күпкырлы. Шулай да, кайсы беренчел? Журналистмы әллә шагыйрәме?**

- Журналистика ул минем яраткан хезмәтем, ә шигърият - күңел халәтем. Гомумән, алар - икесе ике кыйбла. Әйтик, газета журналистикасы ул - вакыт белән дә, күңел халәте белән исәпләшми торган иң тынгысыз хезмәтләрнең берсе. Көн аралаш 8 полосалы басманы тутырып бару өчен, син тәүлек буе йөгерештә, эзләнүдә! Әле бит кайтып язарга да кирәк. Күпме җаваплылык синең өстә: мәгълүмат та җитәрлек туплансын, фактлар да төгәл булсын, журналист фикере, чыгарган нәтиҗәсе дә ярылып ятсын! Ә шигырь, Хәсән ага Туфан әйткәнчә, хис-тойгыларың мөлдерәп ташып түгелгәндә, язмыйча түзеп кала алмаган халәттә генә язылырга тиеш. Яхшымы-яманмы, мин шулай язам. Ә «бармактан суырып» рифмалар төзеп утыруны галибанә Шигърияткә хыянәт итү дип саныйм.

**- Кайчандыр юморескалар язу белән дә мавыккансыз.**

- Әйе, «Якты юл» газетасында эшләгәндә күп язылды алар. Берничә- се «Әрем исе» китабында да урын алды. Авыллар буйлап йөргәндә нинди генә кызык хәлләргә тап булмыйсың! Җаваплырак вазифага алынгач, андый темаларга рәхәтләнеп язарга вакыт калмый башлады. Шулай да әлеге жанрга кайчан да булса кайту исәбем бар.

**- Тәрҗемәләр белән кайчаннан шөгыльләнәсез?**

- «Якты юл»да эшли башлаган көннән. Ике телгә дә тәрҗемә итәм. Шәхси заказлар җитәрлек. Кәрим Караның «Матильда» повестен русчага тәрҗемәләвем белән аеруча горурланам. 2021 елда «Челнинские известия» газетасында басылды. Рус телендәге актуаль әңгәмәләрем шулай ук төрле басмаларда дөнья күрде.

**- Рәзинә апа, инде берничә сүз әдәби мөхәррирлек хакында.**

- Соңгы елларда Азат Хаҗиевның «Чебенле (Тойгузино) авылы татар язмышында», Дамир Таҗиевның «280 елдан соң Туймәтемә кайтам» дигән тарихи-эпик елъязмаларының әдәби мөхәррире булдым. Шулай ук бик четрекле дә, үтә җаваплы да хезмәт.

**- Сез бит әле күп кенә җырлар авторы да.**

- Әйе, бу өлкәдә дә азмы-күпме хезмәтем бар. Ринат Гобәйдуллин, Мөнир Шәрәфетдинов, Мөҗип Зәйнуллин, Рубис Зарипов, Рөстәм Әхмәтханов, Анна Гыйльметдинова, Зөлфия Җиһан, Гөлүзә Зиатдинова белән иҗади хезмәттәшлектә 40ка якын шигыремә көйләр язылды.

**- Соңгы вакытта нинди темалар күңелегезгә аеруча якын?**

- Тормыш, язмыш, дөньяның бүгенге хәвефле халәте турында уйланам, хафаланам, әлбәттә. Туган телебезнең язмышы бик тә борчый. Шул ук вакытта табигать гүзәллегенә дә битараф кала алмыйм. Туган җир, мәхәббәт темасына да яратып иҗат итәм.

**- Сезнең өчен нәрсә ул бәхет?**

- Кадерле кешеләрем - гаиләм, балаларым, оныкларымның исән-имин, бәхетле булуы. Гаиләмә, туганнарыма, дусларыма кирәк булуымны тоюдан алган рәхәтлек, горурлык, җан тынычлыгы, күңел канәгатьлеге. 30-40 ел элек бергә эшләгән хезмәттәшләрем белән бүген дә, ай саен очрашабыз. Әнә шул мизгелләр миңа илһамланып иҗат итү өчен яшәү көче, рух ныклыгы бирә.

Әңгәмәдәш - Сәрия Гарипова